МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.12.2023 Казан ш № 962

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен күченгәндә эшсез гражданнарга һәм башка җиргә күчеп киткәндә эшсез гражданнарга, аларның гаилә әгъзаларына булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 18 февралендәге 78 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен күченгәндә эшсез гражданнарга һәм башка җиргә күчеп киткәндә эшсез гражданнарга, аларның гаилә әгъзаларына булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 18 февралендәге 78 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 16.10.2018 №950, 07.05.2019 №331, 16.11.2019 №1037, 10.02.2020 №82, 22.06.2020 №449, 02.10.2020 №695, 04.06.2021 №396, 28.02.2022 №136 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2023 елның 15 декабрендәге 962 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен күченгәндә эшсез гражданнарга һәм башка җиргә күчеп киткәндә эшсез гражданнарга, аларның гаилә әгъзаларына булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 18 февралендәге 78 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Боерык аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен күченгәндә эшсез гражданнарга һәм үзләренә туры килә торган эш эзләү максатыннан халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга, башка җиргә күчеп киткәндә эшсез гражданнарга һәм үзләренә туры килә торган эш эзләү максатыннан халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга, аларның гаилә әгъзаларына булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында».

преамбулада «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга күчеп китүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп китүдә ярдәм итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең федераль дәүләт стандартын раслау турында» 2013 елның 7 мартындагы 92н номерлы боерыгы белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә «Туры килә торган эш эзләү максатыннан эшсез гражданнарга һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга туры килә торган эш эзләү максатында күченеп китүдә һәм, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, гражданнарга һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп китүдә ярдәм итү» дәүләт хезмәте күрсәтү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру стандартын раслау һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 7 апрелендәге 204н номерлы боерыгының үз көчен югалтуын тану турында» 2022 елның 14 октябрендәге 653н номерлы боерыгы белән» сүзләренә алмаштырырга;

боерыкның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен күченгәндә эшсез гражданнарга һәм үзләренә туры килә торган эш эзләү максатыннан халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән

гражданнарга, башка җиргә күчеп киткәндә эшсез гражданнарга һәм үзләренә туры килә торган эш эзләү максатыннан халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга, аларның гаилә әгъзаларына булышлык күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын (алга таба – Административ регламент) расларга».

боерыкның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Административ регламентның халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен күченгәндә эшсез гражданнарга һәм үзләренә туры килә торган эш эзләү максатыннан халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга, башка җиргә күчеп киткәндә эшсез гражданнарга һәм үзләренә туры килә торган эш эзләү максатыннан халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга, аларның гаилә әгъзаларына булышлык күрсәтү буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) аша күрсәтү өлешендәге пунктлары КФҮ һәм Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары арасында килешү төзелгәннән соң үз көченә керә.

Административ регламент атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен күченгәндә эшсез гражданнарга һәм үзләренә туры килә торган эш эзләү максатыннан халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга, башка җиргә күчеп киткәндә эшсез гражданнарга һәм үзләренә туры килә торган эш эзләү максатыннан халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга, аларның гаилә әгъзаларына булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты»;

Административ регламентның 1-3 бүлекләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен күченгәндә эшсез гражданнарга һәм үзләренә туры килә торган эш эзләү максатыннан халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга, башка җиргә күчеп киткәндә эшсез гражданнарга һәм үзләренә туры килә торган эш эзләү максатыннан халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга, аларның гаилә әгъзаларына булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Административ регламент) халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен күченгәндә эшсез гражданнарга һәм үзләренә туры килә торган эш эзләү максатыннан халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга, башка җиргә күчеп киткәндә эшсез гражданнарга һәм үзләренә туры килә торган эш эзләү максатыннан халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга, аларның гаилә әгъзаларына булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын, тәртибен, административ процедураларның составын, эзлеклелеген һәм аларны башкару срокларын билгели (алга таба – дәүләт хезмәте).

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып түбәндәгеләр тора:

билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнар (алга таба – эшсез гражданнар);

тиешле эш эзләү максатыннан халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнар (алга таба – теркәлгән гражданнар).

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга һәм туры килә торган эш эзләү максатларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга күченгәндә һәм эшсез гражданнарга һәм туры килә торган эш эзләү максатларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашканда ярдәм итү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

2.2.1. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре (алга таба – халыкны эш белән тәэмин итү үзәге) тарафыннан Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлекләре территориясендә яшәү урыны буенча күрсәтелә. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы гамәлгә ашыра.

2.2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) аша бирергә мөмкин.

КФҮ белгече тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм гаризаны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителми.

## 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) башка җирлектә эшкә урнашу өчен гражданинга юллама бирү (киңәш ителә торган үрнәге «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә «Туры килә торган эш эзләү максатыннан эшсез гражданнарга һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга туры килә торган эш эзләү максатында күченеп китүдә һәм, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, гражданнарга һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп китүдә ярдәм итү» дәүләт хезмәте күрсәтү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру стандартын раслау һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 7 апрелендәге 204н

номерлы боерыгының үз көчен югалтуын тану турында» 2022 елның 14 октябрендәге 653н номерлы боерыгы белән расланган Туры килә торган эш эзләү максатыннан эшсез гражданнарга һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга туры килә торган эш эзләү максатында күченеп китүдә һәм, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, гражданнарга һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп китүдә ярдәм итү» дәүләт хезмәте күрсәтү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру стандартының (алга таба – Стандарт) 2 нче кушымтасында китерелгән);

2) халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен гражданинга күченгәндә яки гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченгәндә финанс ярдәме күрсәтү яки аны күрсәтүдән баш тарту.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә «Работа в России» бердәм цифрлы платформасында (алга таба – Бердәм цифрлы платформа), Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган физик затлар регистрында (алга таба – Физик затлар регистры) теркәлә.

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

2.3.4. Эшкә урнашу өчен башка җирлеккә юллау реквизитлары:

халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесенең исеме;

(дәүләт учреждениесенең) урнашкан адресы, телефон номеры, электрон почта адресы;

юридик затның исеме;

шәхси эшкуарның яки физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

(юридик затның) урнашкан адресы, телефон номеры;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

вакантлы вазыйфа белгечлеге;

белешмәләр өчен телефон номеры;

карар кабул итүгә вәкаләтле затның (алга таба – вәкаләтле зат) вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

имза.

Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен гражданинга күченгәндә яки гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченгәндә финанс ярдәме күрсәтү турында карар реквизитлары:

халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесенең исеме;

хезмәт күрсәтү турында караның датасы, номеры;

финанс ярдәме турында шартнамә датасы, номеры;

шәхси эшкуарның яки физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

(юридик затның) урнашкан адресы, телефон номеры;
мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);
карар кабул итүгә вәкаләтле затның (алга таба – вәкаләтле зат) вазыйфасы;
вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);
имза.

Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен гражданинга күченгәндә яки гражданинга һәм аның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченгәндә финанс ярдәме күрсәтүдән баш тарту турында карар реквизитлары:
халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесенең исеме;
хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карарның датасы, номеры;
мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);
карар кабул итүгә вәкаләтле затның (алга таба – вәкаләтле зат) вазыйфасы;
вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);
имза.

2.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):
Бердәм цифрлы платформадан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://www.uslugi.tatarstan.ru (алга таба – Татарстан Республикасы порталы) файдаланып, электрон документ рәвешендә;
мөрәҗәгать итүчегә шәхсән кәгазь чыганакта.

## 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

2.4.1. Дәүләт хезмәте, әгәр гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән бирелгән булса, гражданин мөрәҗәгать иткән көннән алып бер эш көне эчендә бирелә.

2.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм цифрлы платформада шәхси кабинет аша тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә Республика порталындагы шәхси кабинетта (алга таба – шәхси кабинет) күренә торган номер һәм «Документларны тикшерү» статусы беркетелгән көннән соң бер эш көне эчендә күрсәтелә.

2.4.3. Дәүләт хезмәте гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан КФҮ аша тапшырылган очракта, гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар Министрлык тарафыннан теркәлгәннән соң бер эш көне эчендә күрсәтелә.

2.4.4. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы порталында шәхси кабинет

аша тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте, Татарстан Республикасы порталында теркәлгән көннән алып, бер эш көне дәвамында күрсәтелә.

2.4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен бирү (җибәрү) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергән һәм теркәгән көннән алып бер календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Эшсез гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе эшсез гражданин мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

2.4.6. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре финанс ярдәме күрсәтү турында карарны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга һәм туры килә торган эш эзләү максатларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга күченгәндә һәм эшсез гражданнарга һәм туры килә торган эш эзләү максатларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченгәндә финанс ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2012 елның 15 июнендәге 515 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга һәм туры килә торган эш эзләү максатларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга күченгәндә һәм эшсез гражданнарга һәм туры килә торган эш эзләү максатларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченгәндә финанс ярдәме күрсәтү тәртибенең (алга таба – 515 нче Тәртип) 2.1.5-2.1.7, 2.2.5 пунктларында каралган документларны тапшырган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көнлек срокта кабул итәләр.

2.4.7. Инвалид булып торган мөрәҗәгать итүчеләргә дәүләт хезмәте күрсәтү «Инвалидларның федераль реестры» (алга таба – ИФР) федераль дәүләт мәгълүмат системасында булган инвалидлык турында белешмәләр, ә тиешле белешмәләр булмаса, мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләр Федераль медицина-социаль экспертиза учреждениесе (алга таба – МСЭ) тарафыннан бирелгән документны үз инициативалары буенча тапшырмаган очракта һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә шәхси программадан өземтә булмаган очракта, инвалидлар категориясенә караган мөрәҗәгать итүчеләргә дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты гариза теркәлгән көннән алып җиде эш көне тәшкил итә.

ИФР аша инвалидлык турында кирәкле белешмәләрне алу халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан «Ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы) ярдәмендә халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан электрон документ рәвешендә җибәрелә торган ИФР адресына ведомствоара гариза формалаштыру юлы белән халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан башкарыла.

## 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Татарстан Республикасы Порталында түбәндәгеләр урнаштырылган:
дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;
дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;
дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

## 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченүдә ярдәм итеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тәкъдим итә:
- дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) (тәкъдим ителгән үрнәк Стандартка 1 нче кушымтада китерелгән);
- мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документ, аның күчермәсе гаризага теркәлә.
- мөрәҗәгать итүче вәкиленең шәхесен раслаучы документ һәм мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итү хокукына ышаныч кәгазе, мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документ күчермәсе. Күрсәтелгән документларның күчермәләре гаризага теркәлә.
2.6.2. Эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченеп урнашуда ярдәм итеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тәкъдим итә:
- дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (тәкъдим ителә торган үрнәге Стандартка 1 нче кушымтада китерелгән);
- мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документларның (чит ил гражданинының шәхесен һәм таныклыгын таныклаучы документлар, – чит ил гражданины булып торган мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзасы өчен, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документ, – гражданлыгы булмаган зат булып торган мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзасы өчен) билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәләре;
- өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе, мөрәҗәгать итүченең 14 яшенә җитмәгән гаилә әгъзалары тууы турында чит ил дәүләтенең компетентлы органнарыннан бирелгән таныклыкларның күчермәләре һәм аларның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе;
- гражданлык хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклык күчермәсе;
- мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларыннан яки аларның законлы вәкилләреннән (ирекле формада) документлар, түбәндәгеләрне раслый торган:
аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык булуын;
мөрәҗәгать итүченең персональ белешмәләрне халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшырганда алар исеменнән эш йөртүгә вәкаләтле булуын.

Документларның күчермәләре, әгәр алар билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белгече тарафыннан таныклана.

2.6.3. Вакытлыча эшкә урнашу өчен башка җирләргә күченгәндә финанс ярдәме күрсәтү өчен, мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тәкъдим итә:

- исәп-хисап счеты реквизитларын күрсәтеп, 515 нче Тәртипкә 2 нче кушымтадагы форма буенча гариза;

- мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документ, аның күчермәсе гаризага теркәлә;

- мөрәҗәгать итүче вәкиленең шәхесен раслаучы документ һәм мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итү хокукына ышаныч кәгазе, мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документ күчермәсе (мөрәҗәгать итүче вәкиле тарафыннан тапшырылган очракта). Күрсәтелгән документларның күчермәләре гаризага теркәлә.

- 515 нче Тәртипнең 2.1.2. пунктының 2.1.2.1 һәм 2.1.2.2 пунктчаларында каралган чыгымнар турында мәгълүматны раслаучы документларның оригиналы:

- 515 нче Тәртипнең 2.1.2 пункты нигезендә компенсацияләнергә тиешле чыгымнар турында мәгълүматны раслаучы документларның оригиналы (элек 515 нче Тәртипнең 2.1.5 пунктына ярашлы өлешчә компенсация алган);

- банкта яки башка кредит оешмасында ачтырылган шәхси счетны (исәп-хисап счетын) күрсәтеп, документ күчермәсен.

2.6.4. Вакытлыча эшкә урнашу өчен башка җирләргә күченгәндә финанс ярдәме күрсәтү өчен, мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тәкъдим итә:

- исәп-хисап счеты реквизитларын күрсәтеп, 515 нче Тәртипкә 3 нче кушымтадагы форма буенча гариза;

- мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документ, аның күчермәсе гаризага теркәлә;

- мөрәҗәгать итүче вәкиленең шәхесен раслаучы документ һәм мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итү хокукына ышаныч кәгазе, мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документ күчермәсе (мөрәҗәгать итүче вәкиле тарафыннан бирелгән очракта). Күрсәтелгән документларның күчермәләре гаризага теркәлә.

- 515 нче Тәртипнең 2.1.2. пунктының 2.1.2.1 һәм 2.1.2.2 пунктчаларында каралган чыгымнар турында мәгълүматны раслаучы документларның оригиналы:

- 515 нче Тәртипнең 2.1.2 пункты нигезендә компенсацияләнергә тиешле чыгымнар турында мәгълүматны раслаучы документлар оригиналы (элек 515 нче Тәртипнең 2.1.5 һәм 2.1.6 пунктларында каралган гаризалар бирелмәсә);

- банкта яки башка кредит оешмасында ачтырылган шәхси счетны (исәп-хисап счетын) күрсәтеп, документ күчермәсен.

2.6.5. Башка җирләргә эшкә урнашу өчен яңа яшәү урынына күченгәндә финанс ярдәме күрсәтү өчен, мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тәкъдим итә:

- исәп-хисап счеты реквизитларын күрсәтеп, 515 нче Тәртипкә 4 нче кушымтадагы форма буенча гариза;

- мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документ, аның күчермәсе гаризага теркәлә;

- мөрәҗәгать итүче вәкиленең шәхесен раслаучы документ һәм мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итү хокукына ышаныч кәгазе, мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документ күчермәсе (мөрәҗәгать итүче вәкиле тарафыннан тапшырылган очракта). Күрсәтелгән документларның күчермәләре гаризага теркәлә.

- эш бирүче белән төзелгән, эш бирүче тарафыннан расланган хезмәт килешүе күчермәсен;

- мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының күченеп урнашу буенча 515 нче Тәртипнең 2.2.2.1 пунктында каралган чыгымнар турында белешмәләрне раслаучы документларның оригиналлары: транспорт чыгымнары, яңа яшәү урынына барган вакытта тәүлеклек чыгымнары һәм элеккеге яшәү урыныннан яңа яшәү урынына йорт мөлкәтен алып бару бәясен түләү чыгымнары (шартнамәләр, башкарылган эшләр актлары, исәп-хисап-фактуралары, квитанцияләр, касса чеклары һ.б.) турында;

- мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документларның (чит ил гражданинының шәхесен һәм таныклыгын таныклаучы документлар, - чит ил гражданины булган гаилә әгъзасы өчен, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документ, - гражданлыгы булмаган зат булып торучы гаилә әгъзасы өчен) билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәләрен;

- мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларының персональ белешмәләрен тапшырганда аның гаилә әгъзалары исеменнән яки аларның законлы вәкилләре исеменнән эш итүгә вәкаләтле булуын раслаучы документны;

- аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык булуын;

- банкта яки башка кредит оешмасында ачтырылган шәхси счетны (исәп-хисап счетын) күрсәтеп, документ күчермәсен.

2.6.6. Әлеге Регламентның 2.6.3-2.6.5 пунктларында күрсәтелгән документларны теркәгән гариза мөрәҗәгать итүче яки аның вәкиле тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә турыдан-туры тапшырыла яки мөрәҗәгать итүченең ихтыяры буенча, кулга тапшыру турында хәбәр белән заказлы почта хаты итеп җибәрелә.

Документларны теркәп, гаризаны заказлы почта хаты итеп җибәргән очракта, гаризага тапшыру турында хәбәр беләнмөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документның нотариаль рәвештә расланган күчермәсе дә теркәлә.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан агымдагы елның 25 декабреннән соң бирелгән гаризалар каралмый һәм мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылырга тиеш, шулай ук гаризалар күрсәтелгән срокка кадәр бирелгән булып, шул ук вакытта агымдагы елның 25 декабренә кадәр әлеге пунктта каралган, күченгәндә финанс ярдәме күрсәтү турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар тапшырылмаган очракта да.

Эшсез гражданин, туры килә торган эш эзләү максатларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданин Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66[1] статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган, хезмәт эшчәнлеге турында шул эш бирүчедән китү датасын һәм эштән азат ителү көнен раслый торган белешмәләрне һәм (яисә) тиешле рәвештә таныкланган хезмәт

кенәгәсе күчермәсен (2020 елның 1 гыйнварыннан соңгы чор), әлеге пунктта каралган гариза бирелгән көннән соң мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы.

Гариза Татарстан Республикасы порталы аша җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең шәхесен таныклый торган документындагы белешмәләре исәпкә алыну язуы Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (алга таба – БИАС) расланган вакытта тикшерелә.

2.6.7. Электрон рәвештәге гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гади электрон имза куллану турында» 2013 елның 25 гыйнварындагы 33 номерлы карары белән расланган  Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гади электрон имза куллану кагыйдәләре нигезендә алынган гади электрон имза белән яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән яки көчәйтелгән квалификацияле булмаган, тикшерү сертификаты электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада булдырылган һәм кулланыла торган имза белән имзалана.

Гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

Бердәм цифрлы платформада шәхси кабинет аша;

Татарстан Республикасы порталы аша;

КФҮ аша;

халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә, Бердәм цифрлы платформадан файдалану мөмкинлеген тәэмин итеп, шәхсән килгән очракта.

2.6.8. Мөрәҗәгать итүче электрон формада гариза биргәндә булышлык күрсәтүне сорап, халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә яисә КФҮ мөрәҗәгать итә ала.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүчеләргә Бердәм цифрлы платформага, Татарстан Республикасы порталына керү мөмкинлеге бирелә, шулай ук кирәкле консультация ярдәме күрсәтелә.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә мөрәҗәгать иткән затта «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында исәпкә алу язуы булмаса, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге яки КФҮ, халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә мөрәҗәгать итүче зат риза булган очракта, әлеге системада мөрәҗәгать итүченең процедуралар узып бетерүен тәэмин итә.

2.6.9. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәгеләр алына:

- мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документның гамәлдә булуы турында белешмәләр  (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына) (алга таба – ЭЭМ);

- мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларының шәхесен раслаучы документлар турында мәгълүмат (ЭЭМ);

- мөрәҗәгать итүченең 14 яшенә җитмәгән гаилә әгъзаларының тууын дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (ГХАТ органнарына);

- никахны дәүләт теркәве турында мәгълүмат (ГХАТ органнарына);
- аталыкны билгеләү турында мәгълүмат (ГХАТ органнарына);
- гаилә составы турында белешмәләр (гражданнарның тору урыны һәм яшәү урыны буенча теркәү исәбенә алучы ашыруга вәкаләтле оешмаларда);
- баланы опекага алу турында опека һәм попечительлек органы карарындагы мәгълүматлар (опека һәм попечительлек органнарына);
- уллыкка алу турында мәгълүмат (бала уллыкка алынган очракта) («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан);
- Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган гражданның хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондының Татарстан Республикасы территориаль органында (алга таба – РФМИ);
- организмдагы бозылган функцияләрне һәм яшәештәге чикләүләрне исәпкә алып, инвалид өчен МСЭ учреждениесе тарафыннан киңәш ителә торган хезмәт һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлау өчен кирәкле, инвалидлык турындагы белешмәләрне үз эченә алган индивидуаль тернәкләндерү программасыннан өземтә (ИФР);
- мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы мәгълүматлар (Федераль нотариаль палатага, Нотариатның бердәм мәгълүмат системасына);

Мөрәҗәгать итүче әлеге пункттагы белешмәләрдән торган документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә, мөстәкыйль тапшырырга хокуклы.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торган документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигез булып гаризада күрсәтелгән мәгълүматлар һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек тәртибендә алынган мәгълүматлар арасындагы каршылык тора.

2.8.2. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы буенча мөрәҗәгать итүчегә эшкә урнашу өчен башка җиргә күченүдә ярдәм итү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

- документлар белән әлеге Административ регламентның 1.3 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;

Мөрәҗәгать итүченең түбәндәге документларда булган мәгълүматларны тапшырмавы яки булган белешмәләрнең ведомствоара үзара эш итү тәртибендә алынган белешмәләр белән расланмавы:

- мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризасы һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тәкъдиме белән ризалыгы;

- Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алмаштыра торган документ (Россия Федерациясе гражданнары өчен);

- чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгынраслаучы документлар (чит ил гражданнары өчен);

- гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документлар (гражданлыгы булмаган затлар өчен);

- инвалидның хосусый тернәкләндерү программасы яисә инвалидның билгеләнгән тәртиптә бирелә торган хосусый тернәкләндерү яисә абилитацияләү программасы (инвалидлар категориясенә керүче гражданнар өчен);

- почта аша алынган гаризага теркәлгән документларның билгеләнгән тәртиптә таныклап тапшырылмавы.

2.8.3. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы буенча мөрәҗәгать итүчегә эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченүдә ярдәм итү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

- документлар белән әлеге Административ регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;

Мөрәҗәгать итүченең түбәндәге документларда булган мәгълүматларны тапшырмавы яки булган белешмәләрнең ведомствоара үзара эш итү тәртибендә алынган белешмәләр белән расланмавы:

- мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризасы һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тәкъдиме белән ризалыгы;

- Россия Федерациясе гражданины паспорты яки аны алмаштыра торган документ (Россия Федерациясе гражданнары өчен);

- чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын раслаучы документлар (чит ил гражданнары өчен);

- гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документлар (гражданлыгы булмаган затлар өчен);

- инвалидның хосусый тернәкләндерү программасы яисә инвалидның билгеләнгән тәртиптә бирелә торган хосусый тернәкләндерү һәм абилитацияләү программасы (инвалидлар категориясенә керүче гражданнар өчен);

- мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларының шәхесен таныклый торган документлар (чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклаучы документлар, – мөрәҗәгать итүченең чит ил гражданины булып торган гаилә әгъзасы өчен);

- гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклаучы документ, – мөрәҗәгать итүченең гражданлыгы булмаган гаилә әгъзасы өчен;

- гаризага кушылган, почта аша килгән билгеләнгән тәртиптә расланмаган документларны тапшыру.

2.8.4. Эшсез гражданинга, туры килә торган эш эзләү максатларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданинга халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченүдә финанс ярдәме күрсәтү турында шартнамә (алга таба – күчену турында шартнамә) яисә эшсез гражданинга, туры килә торган эш

эзләү максатларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән гражданинга, аның гаилә әгъзаларына халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча эшкә урнаштыру өчен башка җирлеккә күченүдә булышлык күрсәтү турында шартнамә (алга таба – күченеп урнашу турында шартнамә) төзелгән мөрәҗәгать итүчегә финанс ярдәме күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

дөрес булмаган мәгълүмат бирү;

башка җирлеккә яңа яшәү урыны буенча күченеп урнашканда яңа эш урыны буенча теркәлү булмавы;

төзелгән хезмәт килешүе нигезендә хезмәткәрнең эшкә керешүдән баш тартуы;

документларны тапшырмау яки документларны тулы булмаган күләмдә тапшыру.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты

2.10.1. Мөрәҗәгать итүче халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза электрон документ рәвешендә Бердәм цифрлы платформаны кулланып, чират тәртибендә бирелә. Чиратта тору вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.10.2. Вакыты һәм датасы алдан килештерелгән очракта, мөрәҗәгать итүче халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә Бердәм цифрлы платформаны кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны көтү вакыты биш минуттан артмаска тиеш.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

## 2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризасы гариза алынган көнне теркәлә.

2.11.2. Мөрәҗәгать итүченең ял яки эш көне булмаган бәйрәм көнендә электрон рәвештә килгән гаризасы ял яки эш көне булмаган (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.11.3. Күпфункцияле үзәккә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, гариза тапшырылган көнне мөрәҗәгать итүчегә гаризаның җибәрелгән булуын раслый торган теркәү номеры һәм электрон гаризаны тапшыру датасы белән язу бирелә.

2.11.4. Гаризаны Бердәм цифрлы платформа, Татарстан Республикасы порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза теркәлгән көнне Бердәм цифрлы платформада шәхси кабинетында һәм электрон почта буенча гаризаның кабул ителүен раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәлү номеры һәм тапшырылу датасы күрсәтелә.

## 2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат эш бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (гариза һәм эш урыны турында мәгълүмат) үрнәкләре урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

гариплеге булган затка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

инвалидлыгы булган затларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм язулы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-ноктал хәрефләре белән һәм капма-каршы фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н

номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.12.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

дәүләт хезмәтен күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

ишетү буенча гариплеге булган затларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәтеннән файдалануга комачау итә торган каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм капма-каршы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2.12.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

## 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:

эш бирүче өчен шәхси яки гавами (телдән яки язмача) мәгълүмат бирү рәвешендә (шәхсән кабул иткәндә, телефон элемтәсе, электрон почта чараларын кулланып, массакүләм мәгълүмат чараларында мәкаләләр, мәгълүмат материаллары (брошюралар, белешмәлекләр, буклетлар һ.б.) нәшер итү) мәгълүмат алу мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү үрнәкләре турында мәгълүматны мәгълүмат стендларында, Министрлыкның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы порталында, Бердәм цифрлы платформада урнаштыру;

мөрәҗәгать итүче өчен дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаларның һәм башка документларның үрнәкләрен алуны, шул исәптән аларны күчереп алу һәм электрон рәвештә тутыру мөмкинлеге белән дә, тәэмин итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән телефон элемтәсе, электрон почта, Бердәм цифрлы платформа һәм

Татарстан Республикасы порталы, КФҮ, шулай ук Министрлыкның рәсми сайты аша;

КФҮ аша электрон гариза бирү мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү турында Россия Федерациясе законнарындагы мәҗбүри таләпләрнең, дәүләт хезмәте күрсәткәндә әлеге Административ регламент нигезләмәләренең үтәлеше;

дәүләт хезмәте күрсәтү чорларының үтәлүе;

әлеге Административ регламентта билгеләнгән административ процедуралар эзлеклелеген үтәү;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуның нигезлелеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләсе буенча нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы.

2.13.3. Мөрәҗәгать итүченең халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белгечләре белән үзара элемтәгә керү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тапшырганда икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.13.4. Хезмәттәшлекнең дәвамлылыгы әлеге Административ регламент белән билгеләнә.

### 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.14.1. Мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән яки халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тәкъдиме белән халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итә ала.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә мөрәҗәгать итүчегә Бердәм цифрлы платформага, Татарстан Республикасы порталына керү мөмкинлеге бирелә, шулай ук кирәкле консультация ярдәме күрсәтелә.

2.14.2. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм цифрлы платформада, Татарстан Республикасы порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) Бердәм цифрлы платформа, Татарстан Республикасы порталы ярдәмендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирергә;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Бердәм цифрлы платформа, Татарстан Республикасы порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон белдерү формасында алырга;

е) дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган Бердәм цифрлы платформа, Татарстан Республикасы порталы ярдәмендә Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.3. Гариза Бердәм цифрлы платформа, Татарстан Республикасы порталы, КФҮ аша җибәрелергә мөмкин.

2.14.4. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм цифрлы платформада гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.6. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

Бердәм цифрлы платформа.

Татарстан Республикасы порталы.

2.14.7. Электрон документлар түбәндәге форматларда тапшырыла:

а) xml - формалаштырылган документлар өчен;

б) doc, docx, odt - формулалары булмаган, текстлы эчтәлектәге документлар өчен (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш);

в) xls, xlsx, ods - исәпләмәләре булган документлар өчен;

г) pdf, jpg, jpeg - формулаларны һәм (яки) график сурәтләрне дә үз эченә алган (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш), шулай ук график сурәтләре булган документларны да кертеп, текстлы эчтәлектәге документлар өчен.

Документның үз оригиналын сканер аша уздыру юлы белән электрон документны формалаштыру рөхсәт ителә (күчермәләрне куллану рөхсәт ителми), ул 300 - 500 dpi (масштаб 1:1) мөмкинлегендә документ оригиналы ориентациясен саклап гамәлгә ашырыла, түбәндәге режимнарны кулланып:

«каралы-аклы» (документта график сурәтләр һәм (яки) төсле текст булмаган очракта);

«соры төсмерләрдә» (документта төсле график сурәтләрдән аерыла торган график сурәтләр булган очракта);

«төсле» яки «төсне тулы дәрәҗәсендә тапшыру режимы» (документта төсле график сурәтләр яисә төсле текст булган очракта);

чын нөсхәдәге барлык аутентик билгеләрне, атап әйткәндә: затның график имзасын, мөһерне, бланк чатындагы штампны саклап;

файллар саны һәркайсында текстлы һәм (яки) графикалы мәгълүматлар булган документлар санына туры килергә тиеш.

2.14.8. Электрон документлар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

документны һәм документтагы битләр санын идентификацияләү мөмкинлеген; өлешләргә, бүлекләргә, кисәкләргә (кискәчләргә) бүленгән документлар өчен эчтәлек буенча һәм (яки) текстта булган рәсемнәргә һәм таблицаларга күчү мөмкинлеген.

xls, xlsx яки ods форматларында тапшырылырга тиешле документлар аерым электрон документ рәвешендә формалаштырыла.

2.14.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.14.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү (консультация бирүдән һәм гариза кабул итүдән тыш) КФҮ аркылы гамәлгә ашырылмый.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белән КФҮ арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белән КФҮ арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә КФҮ мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе КФҮ эш регламенты белән җайга салына.

2.14.11. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм цифрлы платформадагы шәхси кабинеты аша, Татарстан Республикасы порталында, КФҮ аша алынырга мөмкин.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләрне үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчеләргә вакытлыча эшкә урнашу өчен башка урынга күченүдә ярдәм итү (алга таба – эшкә урнашу өчен башка җиргә күченүдә ярдәм итү);

мөрәҗәгать итүчеләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына эшкә урнашу өчен яңа яшәү урынына күченеп урнашуда ярдәм итү (алга таба – эшкә урнашу өчен башка җиргә күченеп урнашуда ярдәм итү).

3.1.1. Дәүләт хезмәте түбәндәге административ процедураларны (гамәлләрне) үз эченә ала:

гражданин турындагы мәгълүматларны анализлау нигезендә мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдимнәр формалаштыру һәм җибәрү;

мөрәҗәгать итүченең гаризасын кабул итү;

мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү;

консультацияләр үткәрү;

мөрәҗәгать итүче белән башка җирлектә эшкә урнашу вариантларын сайлап алу һәм килештерү;

мөрәҗәгать итүче белән күченү турында шартнамә яки күченеп урнашу турында шартнамә төзү;

мөрәҗәгать итүчегә башка җирлектә эшкә урнашу өчен юллама бирү;

финанс ярдәме күрсәтү:

мөрәҗәгать итүчегә – эшкә урнашу өчен башка җиргә күченергә ярдәм иткән очракта;
мөрәҗәгать итүчегә һәм аның гаилә әгъзаларына – эшкә урнашу өчен башка җирләргә күченергә ярдәм иткән очракта;

техник хатаны төзәтү.

3.2. Гражданин турындагы мәгълүматларны анализлау нигезендә мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдимнәр формалаштыру һәм җибәрү

3.2.1. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдимне халыкны эш белән тәэмин итү үзәге аны формалаштыру көнендә Бердәм цифрлы платформадан файдаланып җибәрә.

3.2.2. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, мөрәҗәгать итүче яшәгән торак пунктның административ-территориаль чикләрендә тиешле эш таба алмаган очракта, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәкъдиме мөрәҗәгать итүченең квалификациясенә туры килгән вакансия Бердәм цифрлы платформада урнаштырылган очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә.

3.2.3. Бердәм цифрлы платформада мөрәҗәгать итүче турында мәгълүматны анализлау.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге теркәлгән мөрәҗәгать итүче турында Бердәм цифрлы платформада булган мәгълүматларга, шулай ук әлеге Административ регламентның 2.6.9 пунктында каралган ведомствоара сорауларны җибәрү юлы белән алынган мәгълүматларга анализ ясый.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән мөрәҗәгать итүче турындагы мәгълүматларны анализлау.

3.2.4. Халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим формалаштыра һәм Бердәм цифрлы платформа аша аны мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге теркәлгән мөрәҗәгать итүчегә Бердәм цифрлы платформа ярдәмендә халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдимне карау нәтиҗәләрен җибәрү һәм тәкъдимне карау нәтиҗәләрен җибәрү срогы турында хәбәр итә.

Үтәү вакыты: процедура тәкъдим формалаштырылган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим юллау, мөрәҗәгать итүчегә тәкъдимне карау нәтиҗәсен юллау турында мәгълүмат бирү.

3.2.5. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү тәкъдименнән баш тартуы, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә әлеге тәкъдимне карау нәтиҗәләрен Бердәм цифрлы платформаны кулланып җибәрмәве.

Үтәү вакыты: процедура тәкъдим җибәрелгән көннән соң өч календарь көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бердәм цифрлы платформада теркәлә.

3.2.6. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдим белән ризалашкан очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге Бердәм цифрлы платформа аша ведомствоара гаризалар юллау юлы белән, шул исәптән

ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан файдаланып, мөрәҗәгать итүче турында әлеге Регламентның 2.6.9 пунктында каралган белешмәләрне сората.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче турындагы мәгълүматларны анализлау.

3.2.7. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге гаризада мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән белешмәләр белән ведомствоара электрон хезмәттәшлек тәртибендә алынган белешмәләр арасында каршылыклар булуы турында мәгълүмат алган очракта, Бердәм цифрлы платформаны файдаланып, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында хәбәр җибәрә, анда түбәндәгеләр була:

гаризада булган мәгълүматка Бердәм цифрлы платформаны кулланып үзгәрешләр кертү тәкъдиме (алга таба – гаризага үзгәрешләр);

белдерүне алган көннән соң өч календарь көн узганчы мөрәҗәгать итүче тарафыннан, Бердәм цифрлы платформаны кулланып, халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә, үз теләге буенча, гаризага үзгәрешләр кертү тәкъдиме белән ризалашу яисә аннан баш тарту турында белдерү җибәрү кирәклеге турында мәгълүмат.

Үтәү вакыты: процедура каршылыкларны ачыклаганнан соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ачыкланган каршылыкларны бетерү.

3.2.8. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге әлеге Административ регламентның 3.2.6 пунктында билгеләнгән вакытта мөрәҗәгать итүченең әлеге тәкъдим белән килешүен алган очракта, гаризага үзгәрешләр Бердәм цифрлы платформада автомат режимда кертелә. Мөрәҗәгать итүче гаризага үзгәрешләрне Бердәм цифрлы платформадан файдаланып, электрон документ рәвешендә имзалый. Әлеге пунктта каралган очракта, гражданин гаризага үзгәрешләрне имзалаган көн гаризаны кабул итү көне булып санала.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризага үзгәрешләр имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризага кабул ителгән үзгәреш.

3.2.9. Мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән тәкъдимнән баш тарткан очракта, мөрәҗәгать итүче гаризаны кире алырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең гаризага үзгәрешләр кертү тәкъдименнән баш тарткан очракта (шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән тәкъдим белән ризалашу яки риза булмавы турында мәгълүмат җибәрелмәгән очракта да), дәүләт хезмәтен күрсәтү туктата.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге мөрәҗәгать итүчегә әлеге Административ регламентның 3.2.5 пунктында күрсәтелгән мәгълүматны тапшырырга тиешле көннән соңга калмыйча дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату турында хәбәр җибәрә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризага үзгәрешләр кертү тәкъдиме белән ризалашуы яки аннан баш тартуы турында хәбәр ирештерелгән көннән соңгы бер эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктату турында хәбәр итү.

3.3. Мөрәҗәгать итүченең гаризасын кабул итү

3.3.1. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге мөрәҗәгать итүченең гаризасын кабул итә һәм Бердәм цифрлы платформаны кулланып, мөрәҗәгать итүчегә гариза җибәргән көнне аның кабул ителүе турында хәбәр җибәрә.

Гаризада мөрәҗәгать итүче бирүче башка җирлектә эш эзләүгә мохтаҗ булу-булмавы, яисә башка җирлектә эш тәкъдим ителүе турында күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче КФҮ мөрәҗәгать иткән очракта, гаризаны халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшыру КФҮ белән халыкны эш белән тәэмин итү үзәге арасындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм чорларда, ләкин гаризаны КФҮ теркәгәннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче гаризаны җибәргән көнне, әмма гаризаны КФҮдә теркәгән көннән соң эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза.

3.3.2. Мөрәҗәгать итүче башка җирлектә эш эзләү кирәклеге турында гаризада күрсәткән очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге гариза кабул ителгән көннән соңгы эш көненнән соңга калмыйча:

консультацияләүне дистанцион формада үткәрү өчен мөрәҗәгать итүче белән күрсәтелгән телефон номеры буенча элемтәгә керә;

гражданинга күченү һәм күченеп урнашу турында консультация үткәрә, аның барышында:

гражданинга башка бирлектә урнашкан оешмаларда вакансияләр һәм буш эш урыннары булуы, башка җирлектәге эш урынында торак белән тәэмин итү мөмкинлеге турында хәбәр итә;

мөрәҗәгать итүче белән күченү яки күченеп урнашу өчен Россия Федерациясе субъектлары исемлеген (3 тән артык түгел) килештерә;

мөрәҗәгать итүчегә күченгәндә яки күченеп урнашканда финанс ярдәме күрсәтү тәртибе һәм шартлары, килешүнең эчтәлеге турында хәбәр итә. Финанс ярдәме күрсәтү тәртибе һәм шартлары турында мәгълүмат, кирәк булганда, гаризада күрсәтелгән электрон почта адресына өстәмә рәвештә җибәрелә;

консультация уздырылган көнне Бердәм цифрлы платформада түбәндәгеләрне терки:

консультациянең формасы, датасы, вакыты, нәтиҗәсе;

мөрәҗәгать итүче белән килешенгән күченү яки күченеп урнашу өчен Россия Федерациясе субъектлары исемлеге;

Бердәм цифрлы платформаны кулланып, мөрәҗәгать итүчегә консультация үткәрү нәтиҗәсендә килешенгән күченү яки күченеп урнашу өчен Россия Федерациясе субъектлары исемлеген җибәрә;

башка җирлектә эш вариантларын сайлап алу белән бәйле рәвештә гражданинның резюмесын төзәтү кирәклеге турында анализ үткәрә.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге Бердәм цифрлы платформада мөрәҗәгать итүче турында мәгълүматны үзгәртү буенча тәкъдимнәр күрсәтеп, резюмега төзәтмәләр кертүнең булмавы яки булуы турында мәгълүматны теркәп бара.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге мөрәҗәгать итүчегә, хәбәрне алган көннең соңгы өч эш көненнән дә соңга калмыйча, резюмега үзгәрешләр кертү кирәклеге турында белешмәләрне теркәү көнендә Бердәм цифрлы платформаны файдаланып, резюмга үзгәрешләр кертү тәкъдиме булган белдерүне җибәрә.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: консультация үткәрү нәтиҗәләрен Бердәм цифрлы платформада теркәү.

3.3.3. Гаризада күрсәтелгән телефон номеры буенча мөрәҗәгать итүче белән дистанцион формада консультацияне уздыру мөмкин булмаган очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, гаризаны кабул иткән көннән соңгы бер эш көненнән дә соңга калмыйча, Бердәм цифрлы платформаны кулланып, консультация уздыру өчен мөрәҗәгать итүче килергә тиешле датаны һәм вакытны билгели.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Бердәм цифрлы платформаны кулланып, мөрәҗәгать итүчегә халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә килергә кирәклеге турында хәбәр җибәрә.

Мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән көндә һәм вакытта халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә консультация өчен килмәгән очракта, Бердәм цифрлы платформаны кулланып, мөрәҗәгать итүче өчен халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә консультациягә кабат килү көнен һәм вакытын билгели, мөрәҗәгать итүчегә тиешле белдерүне җибәрә.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге мөрәҗәгать итүчегә беренче тапкыр билгеләнгән датадан соң шәхси килмәгән көннән башлап 15 календарь көн дәвамында халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә иң күбе ике тапкыр кабат килү көнен билгели.

Мөрәҗәгать итүче консультация узу өчен халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан билгеләнгән даталарда беренче тапкыр шәхсән килмәгән көннән башлап 15 календарь көн дәвамында халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә килмәгән очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге мөрәҗәгать итүченең консультация узу өчен килмәве турындагы белешмәләрне Бердәм цифрлы платформада терки, дәүләт хезмәтен күрсәтү туктатыла.

Дәүләт хезмәте туктатылган көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтенең туктатылуы турында хәбәр җибәрә.

Мөрәҗәгать итүче билгеләнгән көнгә һәм вакытка килсә, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге әлеге Административ регламентның 2.6.1-2.6.5 пунктларында каралган документ булу-булмавын тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат турындагы белешмәләрне эзләтү билгеләрен Физик затлар регистрына кертә һәм электрон рәвештә исәпкә алу документларының тиешле бланкларын таба;

мөрәҗәгать итүченең эшсез гражданин буларак халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә торамы-юкмы икәнлеген, мөрәҗәгать итүченең инвалидлар категориясенә керәме-юкмы икәнлеген ачыклый (халыкны эш белән тәэмин итү үзәгеннән тәкъдим булган һәм мөрәҗәгать итүче халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тәкъдиме белән риза булган очраклардан тыш);

халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең агымдагы архивыннан мөрәҗәгать итүченең шәхси эшен (булган очракта) ала;

консультация үткәрә һәм мөрәҗәгать итүчене килешү формасы белән таныштыра;

Инвалид булып торган мөрәҗәгать итүчеләргә дәүләт хезмәте күрсәтү ИФР булган инвалидлык турында белешмәләр, ә тиешле белешмәләр булмаса, мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Инвалидлар категориясенә керүче эшсез гражданиннарга, инвалидны тернәкләндерү яки абилитацияләү буенча хосусый программаны (алга таба – хосусый программа) яки хосусый программадан федераль медик-социаль экспертиза учреждениесе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бирелгән өземтә (инвалидлар категориясенә карый торган эшсез гражданнар өчен) шәхси инициатива белән тапшырылмаган очракта, һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә хосусый программадан өземтә булмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты гаризаны теркәгән көннән башлап җиде эш көне тәшкил итә.

ИФР системасыннан инвалидлык турында кирәкле белешмәләрне алу халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан ИФР адресына ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, электрон документ формасында җибәрелә торган ведомствоара рәсми мөрәҗәгать формалаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: консультация үткәрү нәтиҗәләрен Физик затлар регистрында, Бердәм цифрлы платформада теркәү.

3.3.4. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге мөрәҗәгать итүче төзәткән көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүче төзәткән резюмены аны эшләп бетерү кирәклеге буенча бәяли. Резюмены камилләштерү нигезләре булган очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге резюмены камилләштерү буенча тәкъдимнәр төзи һәм аларны мөрәҗәгать итүчегә шул ук көнне Бердәм цифрлы платформаны кулланып җибәрә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче резюмега төзәтмәләр керткән көннән соң эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: төзәтмәләр кертелгән резюме.

3.3.5. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге мөрәҗәгать итүче резюмега төзәтмәләр керткән көннән соң яисә, резюмега төзәтмәләр кертү кирәк булмаган очракта, консультация уздырган көннән соң, яисә әлеге Административ регламентның 3.3.1 пунктында резюмега төзәтмәләр кертү өчен күздә тотылган срок тәмамланганнан көннән соң киләсе эш көнендә, мөрәҗәгать итүче резюмега үзгәрешләр кертмәгән очракта, Бердәм цифрлы платформаны кулланып, мөрәҗәгать итүчегә башка җирлектә эшләү вариантларын сайлый:

башка җирлектә эшләү вариантлары исемлегенә Бердәм цифрлы платформада вакансияләрне интеллектуаль эзләү технологиясен кулланып автомат рәвештә формалаштырылган анализны үткәрә һәм мөрәҗәгать итүчегә аеруча килгән вариантларны сайлап ала;

Бердәм цифрлы платформаны кулланып (кирәк булганда), буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар вариантларын өстәмә эзләтә.
Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче резюмега төзәтмәләр керткән көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә консультация үткәргән көннән, мөрәҗәгать итүче резюмега үзгәрешләр кертмәгән очракта, резюмега төзәтмәләр кертү вакыты тәмамланган көннән соң башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: башка җирлектә эш вариантлары исемлеге.

3.3.6. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге башка җирлектә эш вариантларын сайлап алу көнендә мөрәҗәгать итүчегә Бердәм цифрлы платформаны кулланып, түбәндәгеләрне җибәрә:
башка җирлектәге эш вариантларының исемлеген, анда иң күбе 10 эш тәкъдиме (вакансия) була;

башка җирлектә урнашкан оешмаларда вакансияләр һәм буш эш урыннары булуы турында мәгълүматны, шулай ук хезмәткәргә карата куела торган характер, режим, хезмәт шартлары һәм квалификация таләпләре, әлеге оешмаларның хезмәткәрләренә бирелә торган ташламалар, башка җирлектә эш урынында торак белән тәэмин итү мөмкинлеге турында мәгълүматны үз эченә ала торган белешмәләрне;

Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен мөрәҗәгать итүчеләргә һәм мөрәҗәгать итүчеләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына күченгәндә бирелә торган финанс ярдәменең күләме, аны бирү һәм кайтару тәртибе һәм шартлары турында мәгълүматны.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге мөрәҗәгать итүчегә башка җирлектә эш вариантлары исемлеген алганнан соң бер ай эчендә Бердәм цифрлы платформаны кулланып, эш бирүчеләрнең вакансияләренә җавап формалаштыру яки сөйләшүләр үткәрү өчен эш бирүче белән элемтәгә керүнең башка ысулы, шулай ук Бердәм цифрлы платформаны кулланып, халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә сөйләшүләр нәтиҗәләре турында мәгълүмат җибәрү яки башка җирлектә эш вариантларының яңа исемлеген сорап мөрәҗәгать итү кирәклеге турында хәбәр итә.

Үтәү вакыты: процедура эш вариантларын сайлап алган көнне мөрәҗәгать итүче резюмега төзәтмәләр керткән көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә консультация үткәргән көннән, мөрәҗәгать итүче резюмега үзгәрешләр кертмәгән очракта, резюмега төзәтмәләр кертү вакыты тәмамланган көннән соң башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: башка җирлектә эш вариантлары исемлеге, финанс ярдәме һәм аның күләме, аны бирү һәм кире кайтару тәртибе турында мәгълүмат.

3.3.7. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгеннән алынган башка җирлектә эш вариантлары исемлеге нигезендә мөрәҗәгать итүче дистанцион аралашу чараларын, шул исәптән аудио яки видеоэлемтә чараларын кулланып, эш бирүчеләр белән дистанцион формада сөйләшүләр алып бара.

Мөрәҗәгать итүче халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә эш бирүче белән сөйләшүләр нәтиҗәсендә башка җирлектә эш тәкъдим итү турында хәбәр итә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүчегә эш тәкъдим ителгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчедән хәбәр.

3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) җибәрү

3.4.1. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле мәгълүматлар булмаганда, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша белешмәләр сората.

Соратуны җибәрү өчен нигез булып мөрәҗәгать итүченең Бердәм цифрлы платформада теркәлгән гаризасы тора.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге әлеге Административ регламентның 2.6.9 пунктында каралган белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр әзерли һәм җибәрә (шул исәптән электрон хезмәттәшлекнең бердәм ведомствоара системасын кулланып).

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, сорала торган белешмәләрнең исемлеге:

организмдагы бозылган функцияләрне һәм яшәештәге чикләүләрне исәпкә алып, инвалид өчен МСЭ учреждениесе тарафыннан киңәш ителә торган хезмәт һәм һөнәри эшчәнлек төрләрен сайлау өчен кирәкле, инвалидлык турындагы белешмәләрне үз эченә алган индивидуаль тернәкләндерү программасыннан өземтә – ИФР;

мөрәҗәгать итүче турында гражданинны туры килә торган эш эзләү максатларында ул тапшырган документлар һәм (яки) белешмәләр нигезендә халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә теркәгәндә Бердәм цифрлы платформага кертелгән белешмәләр яисә халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан электрон хезмәттәшлекнең бердәм ведомствоара системасы аша мөстәкыйль рәвештә алынган белешмәләр.

мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документның чын булуы турында мәгълүмат – ЭЭМ;

мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларының шәхесен раслаучы документлар турында мәгълүмат – ЭЭМ;

гаилә коруны (аерылышуны) дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр – ГХАТ;

-эшсез гражданинның 14 яшенә җитмәгән гаилә әгъзаларының тууын дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр – ФСХ, ГХАТ;

опека һәм попечительлек органы карарыннан баланы опекага алу турында белешмәләр. Рәсми мөрәҗәгать «Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына җибәрелә;

гражданинның әлеге эш бирүчедәге хезмәт эшчәнлеге турында Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган белешмәләр (2020 елның 1 гыйнварыннан соңгы чорга) – РФМИ.

Әлеге органнарга ведомствоара мәгълүмат сорау турында гарызнамә ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә  дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.

Әлеге Административ регламентның 2.6.9 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре, аларда булган белешмәләр) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Администартив регламентның 2.6.9 пунктында каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар алар карамагында булган органнар тарафыннан бирелә.

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 7 статьясындагы 3 өлеше нигезендә ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләргә җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән алып биш эш көненнән (ике эш көне – дәүләт кадастр исәбенә һәм (яисә) күчемсез мөлкәт объектларына хокукларны дәүләт теркәвенә алган очракта) артып китә алмый. Процедураның нәтиҗәсе булып сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки андагы белешмәләрне) алу яисә ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән баш тарту турында белдерүләр тора.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.

3.5. Мөрәҗәгать итүчеләр белән консультацияләр үткәрү

3.5. Бердәм цифрлы платформада күченү яки күченеп урнашу өчен мөрәҗәгать итүче сайлаган җирлектә буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында мәгълүматлар булмаганда, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге әлеге Административ регламентның 3.3.2 һәм 3.3.3 пунктлары нигезендә күченү яки

күченеп урнашу шартларын төгәлләштерү максатыннан мөрәҗәгать итүче белән консультация үткәрә.

3.5.1. Мөрәҗәгать итүчедән Бердәм цифрлы платформаны кулланып җибәрелгән башка җирлектә эш вариантларының яңа исемлеген алу кирәклеге турында гариза алганда, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге мөрәҗәгать итүчегә Бердәм цифрлы платформаны кулланып эш вариантларының яңа исемлеген җибәрә.

Мөрәҗәгать итүчедән халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә гариза килгән көнне башка җирлектә эш вариантлары булмаса, мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә. Мөрәҗәгать итүче өчен башка җирлектә эшкә урнашу вариантларын сайлау Бердәм цифрлы платформага тиешле вакансия турында мәгълүмат кергән көннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүчедән гариза алу көненнән соң эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: башка җирлектә яңа эш вариантлары исемлеге.

3.5.2. Мөрәҗәгать итүчене шәхсән консультацияләү барышында халыкны эш белән тәэмин итү үзәге эшсез мөрәҗәгать итүчегә, Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында, Бердәм цифрлы платформада булган буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында белешмәләрдән чыгып, эшсез гражданинның һөнәрен вазыйфасын (белгечлеген), эшчәнлек төрен, һөнәри әзерлек һәм квалификация дәрәҗәсен, эш тәҗрибәсен һәм күнекмәләрен, соңгы эш урыны буенча уртача хезмәт хакы күләмен, каршы килә торган һәм мөмкинлекле эш төрләре һәм шартлары турындагы киңәшләрне, эзләнә торган эшкә карата мөрәҗәгать итүченең теләкләрен (хезмәт хакы, эш вакыты режимы, урнашу урыны, хезмәтнең характеры, вазыйфа, һөнәр (белгечлек)), шулай ук хезмәт функциясен үтәү һәм хезмәткәр кандидатурасына карата таләпләрне исәпкә алып, башка җирлектәге эш вариантларын сайлый.

Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрында, Бердәм цифрлы платформада туры килә торган эш вариантлары булган очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белгече буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында белешмәләр булган исемлекне бастырып чыгара һәм аны мөрәҗәгать итүчегә тәкъдим итә.

Башка җирлектә мөрәҗәгать итүчегә туры килә торган эш вариантлары булмаган очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге нәтиҗәне Физик затлар регистрында терки һәм мөрәҗәгать итүчене, башка җирлектә эш вариантларын эзләү өчен, яңадан халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә килергә чакыра.

Эш бирүчедән буш эш урыны (вакантлы вазыйфа) булуы турында мәгълүмат алынган очракта, үзе турындагы белешмәләр Физик затлар регистрында булган мөрәҗәгать итүчегә, аның һөнәри әзерлек дәрәҗәсе хезмәт функциясен үтәүгә карата эш бирүче таләпләренә туры килү шарты белән, телдән (телефон буенча) яисә язмача (электрон документ рәвешендә) өч көн эчендә эшкә юллама рәсмиләштерү һәм бирү өчен халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә килү турында тәкъдим җиткерелә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) турында мәгълүматлар булган исемлек, яисә халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә кабат чакыру.

3.5.3. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге мөрәҗәгать итүче белән буш эш урыннары (вакантлы вазыйфалар) исемлегеннән эш вариантларын килештерә. Мөрәҗәгать итүче халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тәкъдим иткән исемлектән башка җирлектә эш вариантын сайлый. Мөрәҗәгать итүче башка җирлектә берничә эш вариантын сайларга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче башка җирлектә эш вариантын сайламаса, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге нәтиҗәне Физик затлар регистрында терки.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тәкъдим иткән исемлектән эш вариантын сайлау яки тәкъдим ителгән эш вариантларыннан баш тарту, нәтиҗәне Физик затлар регистрында теркәү.

3.5.4. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге мөрәҗәгать итүче тарафыннан башка җирлектә сайланган эш вариантлары нигезендә телефон яки электрон почта аша эш бирүче белән вакансия булуын һәм, эшкә урнаштыру өчен юллау максатында, мөрәҗәгать итүченең кандидатурасын килештерә.

Мөрәҗәгать итүченең кандидатурасын эш бирүче белән килештермәгән очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге мөрәҗәгать итүчегә әлеге Административ регламентның 3.5.1–3.5.3 пунктчаларында каралган гамәлләр эзлеклелеге нигезендә башка җирлектә эш вариантларын сайлауны дәвам итәргә тәкъдим итә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эш бирүче белән эшсез гражданин кандидатурасын килештерү.

3.6. Мөрәҗәгать итүче белән башка җирлектә эшкә урнашу вариантларын сайлап алу һәм килештерү

3.6.1. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге мөрәҗәгать итүчедән эш бирүче белән сөйләшүләр нәтиҗәләре буенча башка җирлектә эшләү тәкъдиме булуы турында мәгълүмат алган көнне яки мөрәҗәгать итүчедән гариза алганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, башка җирлектә эшләү тәкъдиме булуын күрсәтеп:

мөрәҗәгать итүче турында әлеге Административ регламентның 2.6.1-2.6.5 пунктларында күрсәтелгән мәгълүматларны анализлый һәм килешү төзү өчен аларның җитәрлек булу-булмавын билгели;

мөрәҗәгать итүченең эшкә урнашуына ризалыгын раслау өчен эш бирүче белән элемтәгә керә;

Бердәм цифрлы платформада автомат рәвештә формалаштырылган күченү яки күченеп урнашу турында килешү проектын төзәтү юлы белән, күченү яки күченеп урнашу турында килешү проектын рәсмиләштерә;

мөрәҗәгать итүче белән килештерә һәм, Бердәм цифрлы платформаны кулланып, килешү төзү өчен халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә килү датасын билгели;
мөрәҗәгать итүчегә, килешү төзү өчен халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә килү датасы турында мәгълүмат кертеп, хәбәр җибәрә;

мөрәҗәгать итүчегә финанс ярдәме күрсәтү турында карар кабул ителәчәк халыкны эш белән тәэмин итү үзәге турында хәбәр итә.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яки мәгълүматлар) булмаган очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге килешү төзү өчен халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә килү датасы турында хәбәрдә халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә килгәндә гражданин тарафыннан тапшырылырга тиешле мәгълүматлар һәм (яки) документлар исемлеген күрсәтә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүчедәнэш тәкъдиме булу-булмавын күрсәтеп, мәгълүмат алганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчедән гариза алган көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: күченү турында килешү проектын яки күченеп урнашу турында килешү проектын рәсмиләштерү.

Мөрәҗәгать итүче халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә килешүләрне төзү хәбәрдә күрсәтелгән датада һәм вакытта килмәгән очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Бердәм цифрлы платформаны кулланып, мөрәҗәгать итүче өчен халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә кабат килү датасын һәм вакытын билгели, тиешле белдерүне мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге мөрәҗәгать итүчегә беренче тапкыр билгеләнгән датадан соң шәхси килмәгән көннән башлап 15 календарь көн дәвамында халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә иң күбе ике тапкыр кабат килү көнен билгели.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге билгеләгән көннәрдә мөрәҗәгать итүче билгеләнгән беренче көнгә шәхсән килмәгән көннән башлап 15 календарь көн эчендә мөрәҗәгать итүче килешү төзү өчен халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә килмәсә, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге мөрәҗәгать итүченең килешү төзү өчен килемәве турындагы белешмәләрне Бердәм цифрлы платформада терки, дәүләт хезмәте күрсәтү туктатыла, бу хакта халыкны эш белән тәэмин итү үзәге дәүләт хезмәтен күрсәтү туктатылган көннән башлап киләсе эш көненнән соңга калмаган срокта мөрәҗәгать итүчегә тиешле белдерү җибәрә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүчегә шәхсән килү өчен билгеләнгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүченең халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә кабат килү датасын һәм вакытын билгеләү.

3.7. Мөрәҗәгать итүче белән күченү турында шартнамә яки күченеп урнашу турында шартнамә төзү

3.7.1. Мөрәҗәгать итүче билгеләнгән көнне һәм вакытта халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә килешү төзү өчен килгәч, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге мөрәҗәгать итүче белән килешү төзи, ул халыкны эш белән тәэмин итү үзәге

җитәкчесе тарафыннан имзалана. Күченү турында яки күченеп урнашу турында килешүнең шартлы үрнәге Министрлык тарафыннан раслана.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге мөрәҗәгать итүче белән төзелгән килешү турында мәгълүматны Бердәм цифрлы платформага кертә, анда төзелгән килешүләр реестры формалаштырыла һәм алып барыла.

Үтәү вакыты: процедура килешү төзелгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килешү турында мәгълүматны Бердәм цифрлы платформада теркәү.

3.8. Мөрәҗәгать итүчегә башка җирлектә эшкә урнашу өчен юллама бирү

3.8.1. Мөрәҗәгать итүченең кандидатурасын эш бирүче белән килештергәндә ул килешү төзү өчен шәхсән килергә тиешле көндә халыкны эш белән тәэмин итү үзәге:

Стандартка 2 нче кушымтада китерелгән шартлы үрнәк буенча мөрәҗәгать итүчегә башка җирлектә эшкә урнашу өчен юллама рәсмиләштереп бирә;

халыкны эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы буенча эшкә урнашу өчен башка җирлеккә күченгәндә яки күченеп урнашканда финанс ярдәме күрсәтү тәртибе һәм шартлары турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге бирелгән юллама турында мәгълүматны Бердәм цифрлы платформада теркәп бара.

Үтәү вакыты: процедура башка җирлектә эшкә урнашу өчен юллама бирелгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: башка җирлектә эшкә урнашу өчен юллама бирү, мөрәҗәгать итүчегә финанс ярдәме күрсәтү тәртибе һәм шартлары турында мәгълүмат бирү, бирелгән юллама турында мәгълүматны Бердәм цифрлы платформада теркәү.

3.8.2. Мөрәҗәгать итүче килешү төзүдән баш тарткан очракта, шәхсән килү вакытында дәүләт хезмәте күрсәтү туктатыла, бу хакта халыкны эш белән тәэмин итү үзәге мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте туктатылган көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча тиешле хәбәр җибәрә.

Үтәү вакыты: процедура дәүләт хезмәтен күрсәтү туктатылган көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату турында хәбәр җибәрү.

3.8.3. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, мөрәҗәгать итүчене башка җирлектә эшкә урнаштыру турындагы мәгълүматны тикшерә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүчене эшкә урнаштырганнан соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Физик затлар регистрында эшкә урнашу турында мәгълүматны теркәү.

3.9. Мөрәҗәгать итүчегә финанс ярдәме күрсәтү

3.9.1. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, мөрәҗәгать итүчедән башка җирлеккә күченгәндә яки күченеп урнашканда финанс ярдәме күрсәтү турында гариза һәм әлеге Административ регламентның 2.6.3-2.6.5 пунктларында

күрсәтелгән документлар булганда, күченү турында килешү яки күченеп урнашу турында килешү төзелгән мөрәҗәгать итүчегә финанс ярдәме бирү (бирүдән баш тарту) һәм финанс ярдәме билгеләү турында карар кабул итә.

Мөрәҗәгать итүче тотылган чыгымнары турындагы мәгълүматны раслаучы документларны финанс ярдәме күрсәтү турында карарны кабул итәчәк халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшыра.

Мөрәҗәгать итүче тотылган чыгымнар турындагы мәгълүматны раслаучы документларны тапшыру максатыннан, финанс ярдәме күрсәтү турында карар кабул итәчәк халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә килә алмаган очракта, мөрәҗәгать итүче әлеге документларны башка халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшырырга хокуклы. Бердәм цифрлы платформада документлар тапшырылачак халыкны эш белән тәэмин итү үзәге турында тамга куела.

Мөрәҗәгать итүче әлеге Административ регламентның 2.6.3-2.6.5 пунктларында каралган документларны тапшырган халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслап, кирәк булганда документларны финанс ярдәме күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итәчәк башка халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә җибәрә.

